РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» декабрь 2022г. г. Альметьевск № 187

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районы бюджет елкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Бюджет даирәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1013 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Бюджет өлкәсендә аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакындагы карарлары нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районы бюджет елкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 30 октябрендәге 9 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 137 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 167 номерлы, 2022 елның 31 октябрендәге 172 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып),түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.карарның 3 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) вазыйфаи окладның 15 проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;»;

1,2. 3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми), шул исәптән хезмәт хакының бер проценты күләмендә айлык премия;»;

1.3. 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы бюджет елкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Әлмәт муниципаль районы бюджет елкәсе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хаклары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи окладлар, сумнарда |
|---|---|
| Местәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 17 256 |
| Местәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 16 749 |
| Бүлек җитәкчесе | 16 114 |
| Бүлек җитәкчесе урынбасары | 15 353 |
| Баш белгеч | 14 592 |
| Әйдәүче белгеч | 13 830 |
| I категория белгече | 12 942 |
| II категория белгече | 12 815 |
| Белгеч | 12 688» |

1.4. карарга 2 нче кушымта таблицасында «11 958» санын «12 688» саннары белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Н.В. Парфилова).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов